СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район, 422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422036

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**“08” ноябрь 2019 ел** **№149**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**карары**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 110 номерлы карары белән расланган (2019 елның 16 апрелендәге 116 номерлы, үзгәреш белән) Арча муниципаль районы “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Шушмабаш авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 110 номерлы карары белән расланган (2019 елның 16 апрелендәге 116 номерлы үзгәреш белән) Арча муниципаль районының “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 15.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтына (http:arsk.tatarstan.ru) һәм Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Носы авылы, Татарстан урамы, 45 нче йорт адреслары буенча халык күпләп җыела торган урыннардагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы Сәгыйтов В.В.